ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм $8^3$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 1 пунктта «акчалары исәбеннән» сүзләреннән соң «әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
«$1^1$. Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган очракларда һәм тәртиптә әлеге Законның $8^3$ статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән халыкка социаль ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслау шулай ук Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашуга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган акчалар исәбеннән башкарыла ала.»;

2) $8^3$ статьяда:
а) 1 пунктта:

беренче абзацта «60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар)» сүзләрен «пенсия яшендәге» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар)» сүзләрен «пенсия яшендәге» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар)» сүзләрен «пенсия яшендәге» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән социаль ярдәм күрсәтү чаралары шулай ук бергә яши торган 60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), әмма пенсия яшенә җитмәгән, эшләмәүче гражданнардан гына гыйбарәт гаилә составында яшәүче яисә күрсәтелгән категория гражданнарыннан һәм эшләмәүче I һәм (яисә) II төркем инвалидларыннан гыйбарәт гаилә составында яшәүче җитмеш яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган торак урыннар милекчеләренә түбәндәге күләмнәрдә бирелә:

бергә яши торган 60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), әмма пенсия яшенә җитмәгән, эшләмәүче гражданнардан гына гыйбарәт гаилә составында яшәүче яисә күрсәтелгән категория гражданнарыннан һәм эшләмәүче I һәм (яисә) II төркем инвалидларыннан гыйбарәт гаилә составында яшәүче җитмеш яшькә җиткән торак урыннар милекчеләренә – илле процент күләмендә;

бергә яши торган 60 һәм 55 яшькә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар), әмма пенсия яшенә җитмәгән, эшләмәүче гражданнардан гына гыйбарәт гаилә составында яшәүче яисә күрсәтелгән категория гражданнарыннан һәм эшләмәүче I һәм (яисә) II төркем инвалидларыннан гыйбарәт гаилә составында яшәүче сиксән яшькә җиткән торак урыннар милекчеләренә – йөз процент күләмендә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 05 март
№ 10-ТРЗ